**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ УРЫССУ БИСТӘСЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР № 35**

**Урыссу штб**

**«13» 09 2024 ел**

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе Советының
«Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы
2024 елның 25 апрелендәге 5 санлы
Карарына үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 06.10.2003 елгы 131-ФЗ санлы Федераль закон, Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының "Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы 2024 елның 25 апрелендәге 5 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«5) 1,2% түбәндәгеләргә карата :

-Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең мөлкәти мөнәсәбәтләр өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә торган исемлеккә кертелгән гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслары) һәм алардагы урыннар»

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма карар рәсми басылып чыккан көннән кимендә 1 ай узгач, үз көченә керә һәм 2027 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе» муниципаль берәмлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
шәһәр тибындагы Урыссу бистәсе
Башлыгы

А.Ә. Шәфигуллин